ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.06.2026 п.г.т. Алексеевское № 210

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен бетерү турында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 61-64 статьяларына, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясына, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен 26.05.2026 дан эксперт бәяләвенең уңай бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге гражданнары фикерен исәпкә алып(Алексеевск муниципаль районының «Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Красный Баран торак пунктында гражданнар җыенының 30.04.2026 дан № 1 беркетмәсе), Алексеевск муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре челтәренең матди-техник, кадрлар, финанс һәм идарә ресурсларын оптимальләштерү һәм нәтиҗәле файдалану максатында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен бетерергә, ИНН 1605002566/ОГРН 1021605753773. Урнашу урыны: 422914, Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Красный Баран авылы, Центральная урамы, 40 йорт.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен (алга таба – «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ) 2026 елның 15 августына ябу датасын билгеләргә.

3. «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУның бетерү комиссиясе составын расларга (1 нче кушымта).

4. «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ ен бетерү буенча чаралар планын Россия Федерациясе Гражданлык кодексы нигезендә расларга (2 нче кушымта).

5. Россия Федерациясе Граждан кодексының 62 статьясындагы 3 пункты нигезендә әлеге карар үз көченә кергән мизгелдән бетерү комиссиясенә «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ ның эшләре, финанс-хуҗалык эшчәнлеге белән идарә итү вәкаләтләре бетерү чорында күчә дип билгеләргә.

6. «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ се директоры М.Н. Захаровны бетерү комиссиясенең вәкаләтләре имза салу, гариза бирү һәм «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ ен бетерү турында документларны алу хокукы белән бетерүче итеп билгеләргә.

7. «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ се директоры М.Н.Захаровка Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 180 статьясы таләпләре нигезендә учреждение ябылуга бәйле рәвештә, эштән азат ителүгә кимендә ике ай кала, «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ се хезмәткәрләрен булачак эштән азат ителү турында язма рәвештә кисәтергә.

8.«Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ се директоры М.Н.Захаровка 2026 елның 15 августына кадәр «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУсе буенча штат берәмлекләрен кыскарту турында боерык чыгарырга: директор – 1,00; директорның уку – укыту эшләре буенча урынбасары – 0,5; укытучы – 3,78 (шул исәптән тышкы уртак эшчәнлек – 0,33); өстәмә белем бирү педагогы – 0,22; китапханәче – 0,20; пешекче – 1,00; хуҗалык мөдире – 0,50; җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручы – 1,00; каравылчы – 2,00; бина һәм корылмаларга хезмәт күрсәтүче – 0,50.

9. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына https://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_01.06.2026 ел,_ № _210_
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең бетерү комиссиясе составы**

Комиссия рәисе:

Хәмзина Елена Александровна - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.

Комиссия әгъзалары:

Рыдаев Вячеслав Юрьевич - «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы;

Мифтахова Елена Михайловна – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе;

Крохина Надежда Александровна - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МБУ җитәкчесе;

Мохтаров Рәмис Рәисович - Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре профсоюзының Татарстан оешмасы Алексеевск район профсоюз оешмасы рәисе (килештерү буенча);

Павлова Эльвира Нургаяновна - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;

Захаров Михаил Николаевич - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры;

Павлова Любовь Владимировна – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Полянка төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры;

Гайнуллин Радик Робертович – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча).

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_01.06.2026 ел,_ № _210_
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен бетерү чаралары планы**

| № т/б | Чара исеме | Башкару вакыты | Җаваплы башкаручы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Салым инспекциясенә язма хәбәр, «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ ен бетерү турында социаль фондка хәбәрнамә җибәрү | Карар басылып чыкканнан соң 3 көн эчендә | Захаров М.Н. | |
| 2. | «Вестник государственной регистрации» журналында «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ нең бетерелүе турында хәбәр урнаштыру | Беренче басма өчен срок-бетерү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 көннән дә артык түгел.<br>Икенче басма киләсе ай дәвамында | Захаров М.Н. | РФ ГК Ст.57 |
| 3. | «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ нең укучыларының ата-аналарына (законлы вәкилләренә) учреждениенең бетерелүе һәм Зур Полянка төп гомуми белем бирү мәктәбенә күчерелүе турында хәбәр итәргә. Күрсәтелгән хәбәрнамәне «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ нең Интернет челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга. | Гамәлгә куючының күрсәтмә акты басылганнан соң биш эш көне эчендә | Захаров М.Н. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4. | «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ се хезмәткәрләренә учреждение ябылуга бәйле рәвештә эштән азат итү турында хәбәр итү | бетерүгә кимендә 2 ай кала | Захаров М.Н. | |
| 5. | Учреждениене бетерү турында мәгълүматны гамәлдәге лицензияләр реестрына тапшыру | юридик затларның бердәм дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән алып унбиш эш көненнән дә соңга калмыйча. | Захаров М.Н. | |
| 6. | Танылган кредиторларга юридик затны бетерү турында язма хәбәрнамә | бетерү процедурасы башлану турында хәбәрнамә җибәрелгән көннән соң 5 көн эчендә | Крохина Н.А.<br>Захаров М.Н. | |
| 7. | Дебиторларны ачыклау һәм дебиторлык бурычы алу чараларын күрергә | юридик затларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга бетерү процедурасы башлану турында хәбәрнамә җибәрелгәннән соң 10 көн эчендә | Крохина Н.А.<br>Захаров М.Н. | |
| 8. | Мәктәп мөлкәтенә һәм финанс йөкләмәләренә инвентаризация үткәрү, төп чараларның һәм аз кыйммәтле предметларның, дебитор һәм кредитор бурычларының инвентаризация исемлекләрен рәсмиләштерү | әлеге карар басылып чыкканнан соң бер ай эчендә учреждениеләрнең активларына һәм йөкләмәләренә инвентаризация үткәрергә | Крохина Н.А.<br>Захаров М.Н. | «Бухгалтерлык исәбе турында» 21.11.1996 елгы 129-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсе |
| 9. | «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ се мөлкәтенең тапшыру актын әзерләү» | 01.07.2026 га кадәр | Павлова Э.Н.<br>Крохина Н.А.<br>Захаров М.Н. | |
| 10. | «Красный Баран төп | 15.07.2026 га кадәр | Павлова Э.Н. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ нең күчемле мөлкәтен башка муниципаль мәгариф учреждениеләренә тапшыру/яңадан бүлү. Боерык актлары проектларын әзерләү. | | Крохина Н.А.<br>Захаров М.Н. | |
| 11. | «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ нең бинасын, җир кишәрлеген, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге балансына тапшыру | 01.08.2026 га кадәр | Павлова Э.Н.<br>Гайнуллин Р.Р.<br>Захаров М.Н. | |
| 12. | Гамәлгә куючыга ЕГРЮЛдан бетерү турында мәгълүмат бирергә | 01.08.2026 га кадәр | Рыдаев В.Ю.<br>Захаров М.Н. | |
| 13. | Билгеләнгән тәртиптә шәхси счетларны ябу, бюджет ассигнованиеләре лимитларын, финанслауның файдаланылмаган калган күләмнәрен бюджет акчаларын баш бүлүчегә тапшыруны гамәлгә ашыру | 01.08.2026 га кадәр | Мифтахова Е.М.<br>Крохина Н.А. | |
| 14. | Укучыларны «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ ннән «Зур Полянка төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ сенә күчерергә | 01.08.2026 га кадәр | Павлова Л.Н.<br>Захаров М.Н. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15. | «Красный Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ нең архив документларын «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУда саклауга тапшырырга. | 01.08.2026 га кадәр | Рыдаев В.Ю.<br>Захаров М.Н. | |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**